КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 24 март г.Казань № 216

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы авыл торак пунктларында урнашкан дәүләт һәм муниципаль мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмаларында эшкә урнашкан яшь белгечләргә бер тапкыр пособие түләү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 20 декабрь, 1199 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы авыл торак пунктларында урнашкан дәүләт һәм муниципаль мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмаларында эшкә урнашкан яшь белгечләргә бер тапкыр пособие түләү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы авыл торак пунктларында урнашкан дәүләт һәм муниципаль мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмаларында эшкә урнашкан яшь белгечләргә бер тапкыр пособие түләү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 20 декабрь, 1199 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 18 сентябрь, 847 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы авыл торак пунктларында урнашкан дәүләт һәм муниципаль мәдәният, сәнгать һәм кинематография оешмаларында эшкә урнашкан яшь белгечләргә бер тапкыр пособие түләү тәртибенә, 4.1 нче пунктның 4.1.2 нче пунктчасындагы бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«хезмәт кенәгәсе һәм (яки) Россия Федерациясе Хезмәт кодексының $66^1$ статьясы белән билгеләнгән тәртиптә алынган хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин